ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.01.2018 Балык Бистәсе штп. № 04пи

2018 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет һәм башка кулланучылары өчен торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы уставының 46 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә карар бирәм:

1.2018 елның 1 гыйнварыннан түбәндәге тарифларны расларга һәм гамәлгә кертергә:

- 2018 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча гамәлдәге су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләренә тоташтыруга түләү күләме (№1 кушымта);

-2018 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча бюджет һәм башка кулланучыларга каты көнкүреш калдыкларын һәм сыек көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару өчен түләү күләме (2 нче кушымта).

2. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.«2017 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет һәм башка кулланучылары өчен торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында»Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 12.01.2017 №05пи карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д. А. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче Р. Х. Хәбибуллин

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 елның 11
гыйнварындагы № 04пи карарына
кушымта№1

**2018 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча гамәлдәге су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләренә тоташтыруга түләүнең күләме**

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтү төре | Хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Гамәлдәге су белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өчен тариф | тоташтыру | 4500,00 |
| Гамәлдәге су бүлү челтәрләренә тоташтыру өчен тариф | тоташтыру | 4500,00 |

Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма

комитетының 2018 елның 11
гыйнварындагы № 04пи
карарына кушымта№2

**2018 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча бюджет һәм башка кулланучыларга каты көнкүреш калдыкларын һәм сыек көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару өчен түләү күләме**

| Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Тарифлар (сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2018 дән 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 дән 31.12.2018 кадәр |
| Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | м.куб. | 600,0 | 625,0 |
| Каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару | м.куб. | 1168,0 | 1215,0 |